КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

« 17 » 06. 2019 г. № 43-п

“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында журналистларга аккредитация бирү кагыйдәләрен раслау турында

«Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында журналистларга аккредитация бирү кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары И.Ф. Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче А.Р. Зарипов

“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2019 елның 17 июнендәге 43-п номерлы боерыгы белән расланды

**“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында журналистларга аккредитация бирү кагыйдәләре**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Кагыйдәләр «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында журналистларга аккредитация (алга таба – аккредитация, Агентлык) бирү тәртибен җайга сала.

1.2. Аккредитация чикләнмәгән вакытка бирелә. Массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе теләге буенча аккредитация редакциянең нинди дә булса конкрет биремен үтәү өчен кирәкле булган срокка (вакытлы аккредитация) бирелергә мөмкин.

## II. Аккредитация алу хокукы

2.1. Аккредитация алу хокукына милек рәвешенә һәм гамәлгә куючылар составына бәйсез рәвештә массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, шул исәптән чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары ия. Чит ил массакүләм мәгълүмат чарасы журналистына аккредитация алу өчен аның Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгында алынган аккредитациясе раслаучы документы булу шарт.

## III. Аккредитация алу тәртибе

3.1. Аккредитация алуга гариза массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе җитәкчесе имзасы куелып, Агентлык тарафыннан әлеге гаризаны алу фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә кайсы ысул белән Агентлыкка бирелә.

3.2. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), аның вазыйфасы, эш һәм мобиль телефон номерлары, электрон почта

адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкның датасы һәм номеры күрсәтелә.

Вакытлы аккредитациягә гаризада шулай ук редакция йөкләмәсе һәм аны үтәү чоры күрсәтелә.

Чит ил массакүләм мәгълүмат чарасы журналистын аккредитацияләү өчен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгында алынган аккредитацияне раслый торган документларның күчермәләре тапшырыла.

3.3. Әлеге Кагыйдәләрнең 3.2 пункты таләпләренә туры килми торган гаризалар каралмый.

3.4. Аккредитация бирү турында (аккредитация бирүдән баш тарту турында) карар гариза кергән көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча Агентлык җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – Җитәкче) тарафыннан кабул ителә. Мондый карар Җитәкченең тиешле боерыгы чыккан көннән алып икенче эш көненнән дә соңга калмыйча, алу фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә нинди ысул белән гариза җибәргән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә җиткерелә.

3.5. Массакүләм мәгълүмат чарасы махсус характерда (реклама, белешмә, күңел ачу) булган очракта аккредитация бирелми.

3.6. Аккредитация алу турындагы гаризаларны карау, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясенә кабул ителгән карар турында хәбәр итү Агентлыкның матбугат хезмәтләре һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр белән эшләү бүлеге тарафыннан әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

## IV. Аккредитация бирелгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитация алган журналистлар түбәндәге хокукларга ия:

чарада катнашу;

чара турында Агентлык карамагында булган рәсми документларның күчермәләрен алырга (көн тәртибе, пресс-релизлар, мәгълүмат-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материаллар);

бастыру өчен билгеләнгән мәгълүмат-белешмә материаллар белән танышу;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокуклар.

4.2. Аккредитация алган журналистларның бурычлары:

чара регламентын үтәргә һәм ул массакүләм мәгълүмат чаралары өчен махсус оештырылмаган очракта, аның барышына тыкшынмаска;

чарада катнашучыларның эшчәнлегенә комачауламаска;

Агентлыктан бирелгән пресс-релизларны, мәгълүмат-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материалларны кулланганда мәгълүмат чыганагына сылтама ясарга;

һөнәри бурычларны башкарганда Агентлык эшчәнлеге турында дөреслеккә туры килми торган белешмәләр таратмаска.

---